# КАРАР

**23 ноябрь 2021 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 23 ноябрендә 2 этапта түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- янгын сүндерү машинасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- урамнарны яктырту өчен энергияне саклый торган лампалар сатып алу;
- авыл җирлеге торак пунктларында урам юл челтәрен карап тоту;
-Түбән Үрәс авылы суүткәргеч челтәрен ремонтлау; проект-смета документациясе;
- чишмәне төзекләндерү;
- янгын сүндерү гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Түбән Үрәс авылы зиратында хуҗалык будкасын әзерләү һәм урнаштыру?.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 157 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 95 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 95 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Түбән Үрәс авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- янгын сүндерү машинасын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- урамнарны яктырту өчен энергияне саклый торган лампалар сатып алу;
- авыл җирлеге торак пунктларында урам юл челтәрен карап тоту;
- Түбән Үрәс авылы сууткәргеч челтәрен ремонтлау; проект-смета документациясе;
- чишмәне төзекләндерү;
- янгын сүндерү гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Түбән Үрәс авылы зиратында хуҗалык будкасын әзерләү һәм урнаштыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Түбән Үрәс
авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Шамеев

ОГРН 1021607753133
ИНН 1623002015